Юк аягы, юк күзе,
Сөйли, өйрәтә үзе.
Телгә аннан оста юк
Аннан якын дус та юк.
Ул нәрсә?



“КИТАП... Ике катыргы арасына тыгызлап тутырылган чуар кәгазь. Бары шул гына, ә яхшылап уйлап баксаң, ул – адәм балалары уйлап чыгара алган сирәк могҗизаларның берсе. Могҗизаларның могҗизасы”. *Ибраһим Гази*



***Китап –тормыш көзгесе,***
***Китап – бөек тәрбияче.***



**Н.К.Крупская**

***Китап- заманыбыз, тормышыбыз ул.***



***В. Белинский***

# “Китап - кинәшчең синең…”



# 2 апрель - халыкара балалар китабы көне



“Китап – бакча ул, андагы язулар – шул бакчаның гөлләре”

*К. Насыйри*





- *Караңгы урында китап укыма: күзләреңне бозарсың. Укыганда яктылык-күзләреңә түгел, китабыңа төшсен.*

- *Китап битләремне ачканда бармагыңны төкрекләмә, битләремне өстән, почмактан ача башла.*

- *Тукталып калган урында карандаш яки тырнак белән эз ясама, карандаш, ручка шикелле әйберләр кыстырып калдырма, махсус китап кыстыргычлар куллан.*

- *Мине кояшка куйма: югыйсә тышым кибеп кубар, битләре саргаер.*


- *Рәсемнәремне буяма, ертылган битләрне ябыштыр.*

- *Китапханәдән алган китапларыңны вакытында кайтарып бир.*

- *Мине өстәлгә куйганчы, өстәл өстен кара, юеш түгелме, азык калдыклары калмаганмы ?!*

- *Әгәр миндәге әсәрләрне ошатып укыйсың икән, башка иптәшләреңә дә укырга тәкъдим ит.*

TATSHOP.RU



# ӘЛИФБА

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

**Һич тә күңелем ачылмаслык эчем пошса,
Үз - үземне куралмыйча ру-
хым төшсә...
Шул вакытта мин кулыма ки-
тап алам,
Аның изге сәхифәләрен акта-
рам...**



***Г.Тукай***

# Китап турында мәкальләр



- *Китап – белем чишмәсе.*
- *Китап – галим, телсез мөгаллим.*
- *Белем алыйм дисәң ничаклы,*
- *Сөй, хөрмәт ит, ярат китапны.*
- *Китапсыз өй – тәрәзәсез бүлмә.*
- *Китапсыз көн – югалткан көн.*
- *Китап – ул адәм балалары уйлап чыгара алган сирәк могҗизаларның берсе...*
- *Китап – бакча, андагы язулар- шул бакчаның гөлләре.*
- *Күп укысаң, күп белерсең.*





***“ … китапны яратыгыз, ул тормышыгызны җиңеләйтә, уйларның, хисләрнең, вакыйга-ларның чуар һәм ярсу бутал-чыклыгынннан чыгарга дус-ларча ярдәм итә, кешеләрне хөрмәт итәргә өйрәтә …”***

***А.М.Горкий***

